Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге
Мерәс авылы **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«14» ноябрь 2023 ел

№ 03

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Мерәс авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2024 елда яшәү урыны буенча Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Борды авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларының үзара салым буенча взносларын түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Мерәс авылында С.Сәйдәш урамында урам спорт мәйданчыгын сатып алу;
- Мерәс авылында электр материаллары сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру .

2. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Мерәс авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы — Р.Х.Сафина